| | |
|---|---|
| **СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2015 г. с.Новые Чути № 106

Салих авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябрендә кабул ителгән 84 номерлы «физик затлар милкенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

Россия Федерациясе Салым кодексының 399 статьясындагы 2 пункты, 56 статьясы нигезендә Салих авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Салих авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябрендә кабул ителгән 84 номерлы «физик затлар милкенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Ике фатирдан торган күп фатирлы торак йорттагы фатир милекчеләренә ташламаны әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясенең процент өлеше буларак билгеләнә торган салым суммасын киметү рәвешендә бирергә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.»;

3-4 пунктларны 4-5 пункт белән санарга;

2. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында «район турында» бүлегенең «авыл җирлекләре»бүлекчәсендә урнаштырырга.

Салих авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов